ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 август, 2025 ел № 45/7

Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 487-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/13 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2022 елның 25 февралендәге 13/11, 2023 елның 29 июнендәге 25/8, 2023 елның 6 декабрендәге 28/8, 2024 елның 6 декабрендәге 39/9, 2025 елның 27 мартындагы 43/9 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктта «җир законнары таләпләренең» сүзләрен «җирдән файдалану һәм аны саклауга карата таләпләрнең» сүзләренә алыштырырга;

2) 2 пунктың 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең, гражданнарның (алга таба — контрольдәге затлар) җир мөнәсәбәтләрендәге җир объектларында җирдән файдалану һәм аны саклауга карата мәҗбүри таләпләрне (алга таба — мәҗбүри таләпләр) үтәве, аларны үтәмәгән очракта Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында административ җаваплылык каралган;»;

3) 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. Контроль орган муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне тикшерә:

- җир участокларын рөхсәтсез биләмәү турында, җир участокларыннан Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рөхсәт бирә торган документлардан башка файдалану, хуҗалык итү, җирдән файдалану хокукын рөхсәтсез башкаларга тапшыру, шулай ук җир участокларын алмаштыру турында мәҗбүри таләпләрне;

- юридик затлар тарафыннан җир участокларын арендага алу хокукына җир участокларыннан даими (сроксыз) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү яисә җир участокларын милеккә алу турындагы таләпләрне;

- җир участокларыннан максатчан билгеләнеш буенча файдалану турында мәҗбүри таләпләрне;

- авыл хуҗалыгы җитештерүе, торак һәм башка төзелеш максатында билгеләнгән җир участокларыннан мәҗбүри файдалану турында мәҗбүри таләпләрне («Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә авыл хуҗалыгы җитештерүе яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе белән бәйле башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен җайга салына торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдәге җир участокларын мәҗбүри файдалануга бәйле таләпләрне үтәүдән тыш);

- җир биләүчеләр, җирдән файдаланучылар һәм җир участокларын арендалаучылар тарафыннан граждан законнары һәм мәҗбүри таләпләр белән билгеләнгән җир участокларын үзләштерү срокларын;

- җир участокларын арендалаучылар тарафыннан арендалау шартнамәсе шартларын үтәүне;

- җирләрне вакытында кайтаруны;

- җирләрнең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес белешмәләр бирүне;

- җирләрдән файдалану мәсьәләләре буенча законнарның башка таләпләрен үтәүне.»;

4) 33 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«33. Мәҗбүри профилактик визит мәҗбүри таләпләрне үтәүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыруга керешкән контрольдәге затларга карата мондый эшчәнлек башланганнан соң бер ел эчендә үткәрелә.»;

5) 66 пунктта:

- 2 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясе законнарында административ һәм башка җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозу очрагы ачыкланганда, 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, актта мондый хокук бозу хакында күрсәтелә. Контроль органның вазыйфаи заты дәүләт җир күзәтчелеге органына контрольдәге зат белән берлектә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында контроль чарасын уздыру нәтиҗәсендә төзелгән актның күчермәсен җибәрә. Контроль орган җирдән файдалану һәм саклауга карата, шул исәптән мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә мөмкин;»;

6) түбәндәге эчтәлектәге 66.1 пункт өстәргә:

«66.1. Контроль чара үткәргәндә Татарстан Республикасы законнарында административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган бозу өчен җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турында кодексы, Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев